КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ПО ОХРАНЕ ОБЪЕКТОВ
КУЛЬТУРНОГО НАСЛЕДИЯ

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МӘДӘНИ МИРАС
ОБЪЕКТЛАРЫН САКЛАУ
КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

13.07.2026 Казан шәһәре 454-П

Хуҗалык буенча үзләштерелергә тиешле җир кишәрлегенә дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасы актына бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

«Россия Федерациясе халыклары мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләре) турында» 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы федераль закон, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика башкарма хакимияте органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын әзерләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану хакында» 2022 елның 28 февралендәге 175 номерлы карары нигезендә боерык бирәм:

1. Хуҗалык буенча үзләштерелергә тиешле җир кишәрлегенә дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасы актына бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын (кушымтада бирелә) расларга.
2. Татарстан Республикасы Мәдәни мирас объектларын саклау комитетының «Хуҗалык буенча үзләштерелергә тиешле җир кишәрлегенә дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасы актына бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2024 елның 23 сентябрендәге 470-П номерлы боерыгын үз көчен югалткан дип танырга.

Рәис И.Н.Гущин

Татарстан Республикасы Мәдәни мирас объектларын саклау комитетының 2026 елның 13 июлендәге 454-П номерлы боерыгы белән расланды

Хуҗалык буенча үзләштерелергә тиешле җир кишәрлегенә дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасы актына бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Хуҗалык буенча үзләштерелергә тиешле җир кишәрлегенә дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасы актына бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең әлеге Административ регламенты (алга таба – Регламент) дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатын һәм аннан файдалану мөмкинлеген арттыру максатларында эшләнгән, җир, төзелеш, мелиорация, хуҗалык эшләре йогынтысына дучар булган җир кишәрлегенә дәүләт тарихи-мәдәни экспертиза актына бәяләмә бирү вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда гамәлләрнең стандартын, вакытларын һәм эзлеклелеген билгели (алга таба – дәүләт хезмәте).

Татарстан Республикасы Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты түбәндәге объектларга карата хуҗалык буенча үзләштерелергә тиешле җир кишәрлегенә дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасы актын (алга таба – ГИКЭ акты) карый:

күрсәтелгән җирләр «Россия Федерациясе халыклары мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләре) турында» федераль законның (алга таба – 73-ФЗ номерлы федераль закон) 9 статьясындагы 1 пунктының $34^2$ пунктчасы нигезендә расланган территорияләр чикләрендә урнашкан очракта, урманнардан файдалану буенча Россия Федерациясе Урман кодексының 25 статьясында каралган җир, төзелеш, мелиорация, хуҗалык эшләренә (Россия Федерациясе Урман кодексының 25 статьясындагы 1 өлешенең 3, 4 һәм 7 пунктларында күрсәтелгән эшләрдән тыш) һәм башка эшләргә йогынты ясарга тиешле җирләр;

тикшеренүләрнең нәтиҗәләрен үз эченә алган, башкарылган археологик кыр эшләре турындагы фәнни хисаплардан тыш, җир, төзелеш, мелиорация һәм (яисә) хуҗалык эшләре, Россия Федерациясе Урман кодексының 25 статьясында каралган урманнардан файдалану буенча эшләр һәм башка төрле эшләр (Россия Федерациясе Урман кодексының 25 статьясындагы 1 өлешенең 3, 4 һәм 7 пунктларында күрсәтелгән эшләрдән тыш) йогынтысына дучар булган җир кишәрлекләрендә мәдәни мирас объекты билгеләренә ия объектларның булуы яисә булмавы билгеләнә торган документация.

Шартлы билгеләр һәм кыскартулар исемлеге шушы Регламентның 1 нче кушымтасында китерелгән.

1.2. Дәүләт хезмәте гражданнарга, шәхси эшкуарларга, юридик затларга (алга таба – мөрәҗәгать итүче) күрсәтелә.

Мөрәҗәгать итүчеләр исеменнән законнарда билгеләнгән тәртиптә бирелгән

ышанычнамә нигезендә эш итүче затлар (алга таба – мөрәҗәгать итүченең вәкиле) эш итә ала.

1.3. Дәүләт хезмәте мөрәҗәгать итүчегә алар турында белешмәләр «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында (http://www.gosuslugi.ru/) (алга таба – Бердәм портал), шулай ук «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) федераль реестры» федераль дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырыла торган мөрәҗәгать итүчеләрнең категорияләре (билгеләре) нигезендә күрсәтелә.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

2.1. Дәүләт хезмәте атамасы.

Хуҗалык буенча үзләштерелергә тиешле җир кишәрлегенә дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасы актына бәяләмә бирү.

2.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның исеме.

Татарстан Республикасы Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты (алга таба – Комитет).

2.3. Дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсе.

2.3.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтүнең нәтиҗәсе булып дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасы актына бәяләмә (алга таба – бәяләмә) тора, ул 6 нчы кушымтадагы форма буенча рәсмиләштерелә.

Бәяләмә Комитет бланкында рәсмиләштерелә.

Мәгълүмат системасында дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буларак реестр язуын формалаштыру каралмаган.

2.3.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе аны алу буенча сайланган ысул белән мөрәҗәгать итүчегә бирелә (җибәрелә):

язмача формада мөрәҗәгать итүчегә шәхсән яисә почта аша;

электрон документ формасында яки мөрәҗәгать итүченең Бердәм порталда яки Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында (алга таба – Республика порталы) (https://uslugi.tatarstan.ru/) шәхси кабинетына;

үзара хезмәттәшлек турында тиешле килешү булганда, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре (алга таба – КФҮ) аша.

2.3.3. Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен кәгазь документ нөсхәсе рәвешендә алырга хокуклы.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен кәгазь чыганакта алу өчен мөрәҗәгать итүче Комитетка мөрәҗәгать итә.

2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү срогы.

2.4.1. Мөрәҗәгать итүчеләрнең барлык категорияләре (билгеләре) өчен дәүләт хезмәте күрсәтүнең максималь срогы, әгәр дәүләт хезмәтен күрсәтү турындагы гарызнамә һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан Комитетка шәхсән яисә почта аша тапшырылган булса, гарызнамә теркәлгән көннән алып 15 эш көне тәшкил итә.

2.4.2. Мөрәҗәгать итүчеләрнең барлык категорияләре (билгеләре) өчен дәүләт

хезмәте күрсәтүнең максималь вакыты, дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гарызнамә һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан Бердәм портал, Республика порталы аша тапшырылган очракта, гарызнамәгә эшләр номенклатурасы һәм Бердәм порталда, Республика порталында мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинетында чагылдырылган «Документларны тикшерү» статусы нигезендә номер бирелгән көннән алып 15 эш көне тәшкил итә.

2.4.3. Мөрәҗәгать итүчеләрнең барлык категорияләре (билгеләре) өчен дәүләт хезмәте күрсәтүнең максималь срогы, дәүләт хезмәтен күрсәтү турындагы гарызнамә һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан КФҮ ярдәмендә тапшырылган булса, гарызнамә теркәлгән көннән алып 15 эш көнен тәшкил итә, шулай ук КФҮ регламентында каралган срокны исәпкә ала.

2.5. Дәүләт хезмәтен күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән алына торган түләү күләме һәм аны алу ысуллары.

Дәүләт хезмәтен күрсәткән өчен түләү алу Россия Федерациясе законнарында каралмаган.

2.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гарызнамә тапшырганда яисә мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь вакыты.

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гарызнамә мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылганда һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсен алганда чират көтүнең иң күп вакыты – 15 минуттан артык түгел.

Мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән.

2.7. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гарызнамәсен теркәүгә алу чоры.

2.7.1. Комитетка шәхсән мөрәҗәгать иткәндә, гарызнамә кергән көнне үк теркәлә.

2.7.2. Гарызнамәне почта аша җибәргәндә, гарызнамә кергән көнне теркәлә.

2.7.3. Эш көннәрендә Бердәм портал, Республика порталы аша җибәрелгән гарызнамә Комитет тарафыннан кабул ителгән көнне үк теркәлә.

Гарызнамәне Бердәм портал, Республика порталы аша җибәргәндә, мөрәҗәгать итүче гарызнамә биргән көнне Бердәм порталның, Республика порталының шәхси кабинетында гарызнамәнең алынуын раслый торган, аның теркәлү номеры һәм гарызнамә бирү датасы күрсәтелгән хәбәр ала.

2.7.4. КФҮ шәхсән мөрәҗәгать иткәндә, гарызнамә бирелгән көнне мөрәҗәгать итүчегә КФҮ автоматлаштырылган мәгълүмат системасыннан гарызнамәнең җибәрелгәнлеген раслаучы теркәү номеры һәм аны тапшыру датасы белән язу бирелә.

Гарызнамәне һәм теркәлә торган документларны Комитет белән КФҮ арасында үзара хезмәттәшлек турында килешүдә билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда Комитетка тапшыру тәэмин ителә.

Комитетта КФҮ аша килгән гарызнамә кабул ителгән көнне үк теркәлә.

2.7.5. Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә килгән гарызнамә ял (бәйрәм) көненнән соң килүче эш көнендә теркәлә.

2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга карата таләпләр.

Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга таләпләр Комитетның рәсми

сайтында, шулай ук Бердәм порталда, Республика порталында урнаштырылган.

2.9. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең мөмкинлекле һәм сыйфатлы булу күрсәткечләре.

Дәүләт хезмәтеннән файдалану һәм сыйфат күрсәткечләре Комитетның рәсми сайтында, шулай ук Бердәм порталда, Республика порталында урнаштырылган.

2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә башка таләпләр, шул исәптән:

күпфункцияле үзәкләрдә дәүләт хезмәте күрсәтүнең үзенчәлекләрен һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтүнең үзенчәлекләрен исәпкә ала торган;

Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә дәүләт хезмәте турында белешмәләр бирү турында.

2.10.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

2.10.2. Консультация мөрәҗәгать итүче Комитетка шәхсән, телефон һәм почта аша мөрәҗәгать иткәндә бирелә.

2.10.3. Дәүләт хезмәтен КФҮ аша күрсәтү КФҮ белән Комитет арасында үзара хезмәттәшлек турында килешү булганда гамәлгә ашырыла.

Дәүләт хезмәте, мөрәҗәгать итүче ихтыярына карап, аның яшәгән урынына яки фактта яшәгән (торган) урынына бәйсез рәвештә, теләсә кайсы КФҮ экстерриториаль принцип буенча урнашу урыны күрсәтелә.

КФҮ дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны һәм (яисә) мәгълүматны соратып алудан баш тарту турында карарлар кабул итәргә хокуклы түгел.

КФҮ аша мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү, шул исәптән дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнар тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча КФҮ җибәрелгән электрон документларның эчтәлеген раслый торган кәгазьдә документлар бирү мөмкинлеге каралган.

Документларны бирү, кәгазьдә язуны һәм дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнарның мәгълүмат системаларыннан өземтәләрне таныклауны да кертеп, каралмаган.

2.10.4. Электрон рәвештә дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүче хокуклы:

дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында Бердәм порталда һәм Республика порталында урнаштырылган мәгълүматны алырга;

гарызнамзне һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны, шул исәптән электрон үрнәкләре элегрәк "Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында" 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясының 1 өлешендәге $7^2$ пункты нигезендә таныкланган документларны һәм мәгълүматны Бердәм порталдан, Республика порталыннан файдаланып тапшырырга;

электрон рәвештә бирелгән гарызнамәне үтәүнең барышы турында белешмәләр алырга;

дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфатына бәя бирергә;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ рәвешендә алырга;

Бердәм портал һәм (яки) Республика порталы, дәүләт хезмәтләре күрсәтә торган органнар, аларның вазыйфаи затлары тарафыннан дәүләт хезмәте

күрсәтелгәндә кабул ителгән карарларга һәм кылынган гамәлләргә (гамәл кылмауга) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү процессын тәэмин итә торган федераль дәүләт мәгълүмат системасы порталы ярдәмендә Комитет, шулай ук аның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре карарына һәм гамәленә (гамәл кылмавына) шикаять бирергә.

Гарызнамәне формалаштыру, гарызнамәне өстәмә рәвештә нинди дә булса башка формада тапшыру зарурлыгыннан тыш, Бердәм порталда, Республика порталында гарызнамәнең электрон формасын тутыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

2.10.5. Гарызнамәне төзегәндә түбәндәгеләр тәэмин ителә:

1) хезмәт күрсәтү өчен кирәкле гарызнамәнең һәм башка документларның күчермәләрен алу һәм саклап кую мөмкинлеге;

2) берничә мөрәҗәгать итүче тарафыннан күмәк гарызнамә җибәрүне күздә тоткан хезмәтләр күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткәндә, берничә мөрәҗәгать итүче тарафыннан гарызнамәнең бер электрон формасын тутыру мөмкинлеге;

3) гарызнамәнең электрон формасы күчермәсен кәгазьдә бастырып чыгару;

4) файдаланучы ихтыярына карап, шул исәптән гарызнамәнең электрон формасына ялгыш керткәндә һәм күрсәткечләрне яңадан кертү зарурлыгы булганда да, теләсә кайсы вакытта электрон гарызнамә рәвешенә элегрәк кертелгән күрсәткечләрне саклау;

5) мөрәҗәгать итүче белешмәләрне кертә башлаганчы, Бердәм идентификация һәм аутентификация системасында (алга таба – БИАС) урнаштырылган белешмәләрдән һәм Бердәм порталда, Республика порталында бастырып чыгарылган белешмәләрдән файдаланып, Бердәм идентификация һәм аутентификация системасында булмаган белешмәләргә кагылышлы өлешендә гарызнамәнең электрон рәвешендәге кырларын тутыру;

6) элегрәк кертелгән мәгълүматларны югалтмыйча, электрон гарызнамә формасын тутыруның теләсә кайсы этапларына яңадан әйләнеп кайту;

7) кимендә бер ел дәвамында элегрәк тапшырылган гарызнамәләрне мөрәҗәгать итүче тарафыннан карау мөмкинлеге, шулай ук өлешчә тутырылган гарызнамәләр буенча – кимендә 3 ай дәвамында.

2.10.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла.

2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге.

Әлеге Регламентның 3 нче кушымтасында дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге китерелгән, түбәндәгечә бүленешләр белән:

мөрәҗәгать итүче үзе тапшыра торган, дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле, мөрәҗәгать итүче үз инициативасы белән тапшырырга хокуклы булган, ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында тапшырылырга тиешле документлар.

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гарызнамә рәвеше әлеге Регламентның 5 нче

кушымтасында китерелгән.

2.12. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гарызнамәне һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге.

2.12.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтү турындагы гарызнамәне һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булып түбәндәгеләр тора:

а) дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гарызнамә рәвешендә мәҗбүри кырларны дөрес тутырмау (төгәл түгел, дөрес яисә тулысынча тутырмау), шул исәптән Бердәм порталда, Республика порталында гарызнамәнең интерактив рәвешендә дә;

б) тапшырылган документлар дәүләт хезмәтен сорап мөрәҗәгать итү вакытына үз көчен югалткан (шәхесне таныклаучы документ, мөрәҗәгать итүче вәкиле вәкаләтләрен таныклаучы документ);

в) мөрәҗәгать итүче тарафыннан кәгазьдә тапшырылган документларда Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган чистартылган һәм текстны төзәткән урыннар булуы;

г) электрон рәвештә тапшырылган документларда дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлардагы мәгълүматны һәм белешмәләрне тулы күләмдә файдаланырга мөмкинлек бирми торган зарарланган урыннар булуы;

д) электрон рәвештәге гарызнамә һәм башка документлар электрон имза белән «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы федераль закон таләпләрен бозып имзаланган.

2.12.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр законнарда каралмаган.

2.12.3. Законнарда дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр каралмаган.

2.12.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гарызнамәне һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору яки дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге әлеге Регламентның 4 нче кушымтасында китерелгән.

## 3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм үтәлү сроклары.

3.1. Дәүләт хезмәтен күрсәткәндә гамәлгә ашырыла торган административ процедуралар исемлеге:

мөрәҗәгать итүчене профильләштерү;

гарызнамәне, дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар һәм (яисә) мәгълүматны кабул итү;

иҗтимагый фикер алышулар үткәрү, иҗтимагый фикер алышулар нәтиҗәләрен эшкәртү (бәяләү процедурасы);

дәүләт хезмәте күрсәтү турында карар кабул итү;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү.

3.2. Мөрәҗәгать итүчене профильләштерү

3.2.1. Мөрәҗәгать итүчене профильләштерү Бердәм портал яисә Республика порталы ярдәмендә, гарызнамәнең документар формасын (мөрәҗәгать итүче тапшырган документларны) карау юлы белән гамәлгә ашырыла һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен мөрәҗәгать итүченең категориясен (билгеләрен) билгеләү өчен җибәрелә.

3.2.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен мөрәҗәгать итүченең категориясен (билгеләрен) билгеләү ысуллары һәм тәртибе:

мөрәҗәгать итүчедән сораштыру (телдән анкета бирү);

мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган документларны (белешмәләрне) карау;

мөрәҗәгать итүченең Бердәм портал яки Республика порталы эксперт системасы аша узуы.

Мөрәҗәгать итүчеләрнең категорияләре (билгеләре) идентификаторлары әлеге Регламентның 2 нче кушымтасында китерелгән.

3.3. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле гарызнамәне, документларны һәм (яисә) мәгълүматны кабул итү.

3.3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гарызнамә рәвеше әлеге Регламентның 5 нче кушымтасында китерелгән.

Күрсәтелгән гарызнамәне һәм документларны бирү ысулларын күрсәтеп, дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге шушы Регламентка 3 нче кушымтада китерелгән.

3.3.2. Мөрәҗәгать итүченең шәхесен билгеләү ысуллары:

Комитетта, КФҮ – шәхесне таныклаучы документ тапшыру юлы белән;

документларны Бердәм портал, Республика порталы аша тапшырганда – БИАС расланган исәпкә алу язуын төзегәндә формалаштырылган белешмәләр аша.

3.3.3. Мөрәҗәгать итүченең категорияләрен (билгеләрен) исәпкә алып, гарызнамәне һәм дәүләт хезмәтен күрсәткәндә кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге әлеге Регламентка 4 нче кушымтада китерелгән.

3.3.4. Мөрәҗәгать итүченең яшәү урынына яисә тору урынына (физик затлар өчен, шәхси эшкуарларны да кертеп) яисә урнашкан урынына (юридик затлар өчен) бәйсез рәвештә, аның сайлавы буенча дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гарызнамәне яки документларны һәм (яисә) мәгълүматны Комитет яки КФҮ тарафыннан кабул итү мөмкинлеге каралган.

3.3.5. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле гарызнамәне, документларны һәм (яисә) мәгълүматны теркәү вакыты:

Комитетка шәхсән мөрәҗәгать иткәндә, теркәү гарызнамә кергән көнне башкарыла;

Бердәм портал, Республика порталы аша гарызнамә җибәргәндә – дәүләт хезмәте күрсәтү турында гарызнамә кергән көнне;

гарызнамә почта аша килгәндә – гарызнамә килгән көнне;

КФҮ аша кергәндә – КФҮ аша кергән көнне.

Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә килгән гарызнамә ял (бәйрәм) көненнән соң килүче эш көнендә теркәлә.

3.4. Иҗтимагый фикер алышулар уздыру, иҗтимагый фикер алышулар нәтиҗәләрен эшкәртү (бәяләү процедурасы).

3.4.1. Административ гамәлләрнең эчтәлеге.

а) иҗтимагый фикер алышу өчен ГИКЭ актын урнаштыру.

Комитет гарызнамә теркәлгән көннән алып өч эш көне эчендә ГИКЭ актын Комитетның рәсми сайтында иҗтимагый фикер алышу уздыру өчен урнаштыра.

ГИКЭ акты белән бергә Комитетның рәсми сайтында тәкъдимнәр кабул итә башлау һәм тәмамлану датасы турында мәгълүмат урнаштырыла.

б) тәкъдимнәрне кабул итү һәм карау.

Комитет электрон формада (Комитетның электрон почтасы адресына ( (https://okn.tatarstan.ru/arheologiya-akti-gike.htm)) яки кәгазь чыганакта (почта аша яисә кулдан тапшырылган) кергән тәкъдимнәрне кабул итә һәм карый.

Тәкъдимнәрне кабул итү срогы ГИКЭ акты Комитетның рәсми сайтында урнаштырылган көннән алып җиде эш көнен тәшкил итә.

Күрсәтелгән срок дәвамында Комитет кергән тәкъдимнәрне эшкәртә, аларның нигезлелеген һәм мәдәни мирас объектлары турындагы законнар таләпләренә туры килүен тикшерә.

в) Тәкъдимнәр җыелмасын әзерләү.

Комитет иҗтимагый фикер алышу тәмамланганнан соң өч эш көне эчендә кергән тәкъдимнәр җыелмасын төзи, анда түбәндәгеләр күрсәтелә:

кергән тәкъдимнәрнең эчтәлеге;

кергән тәкъдимнәр буенча Комитет позициясе (кабул ителде, кире кагылды);

тәкъдимнәр буенча кабул ителгән карарны нигезләү.

г) Тәкъдимнәр җыелмасын урнаштыру.

Комитет тәкъдимнәр җыелмасын Комитетның рәсми сайтына Комитетның вәкаләтле вазыйфаи заты имза салган көнне урнаштыра.

3.5. Административ процедураны башлау өчен дәүләт хезмәте күрсәтү турында карар кабул итү.

3.5.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләре каралмаган.

3.5.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы карар гарызнамә теркәлгән көннән алып 15 эш көненнән дә соңга калмыйча кабул ителә.

3.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү.

3.6.1. Комитетның вазыйфаи заты гарызнамәдә күрсәтелгән ысул белән мөрәҗәгать итүчегә ГИКЭ актына (дәүләт хезмәте нәтиҗәсенә) бәяләмә бирүне (җибәрүне) тәэмин итә.

а) Нәтиҗәне электрон документ рәвешендә җибәрү:

Бердәм порталда мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинетына;

Республика порталында мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинетына.

Бәяләмәгә Комитет рәисе имза куя яисә ул вәкаләт биргән вазыйфаи затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы куела.

б) Нәтиҗәне кәгазьдә язма рәвештә бирү:

мөрәҗәгать итүчегә шәхсән (Комитетка мөрәҗәгать иткәндә) – бирү гарызнамәгә мөрәҗәгать итүченең кулын куйдыртып гамәлгә ашырыла;

почта юлламасы белән – бәяләмә гарызнамәдә күрсәтелгән почта адресына җибәрелә.

в) Нәтиҗәне КФҮ аша бирү:

Комитет дәүләт хезмәте нәтиҗәсен үзара хезмәттәшлек турында килешүдә билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда электрон рәвештә КФҮ тапшыра.

3.6.2. Административ процедураны үтәү вакыты:

нәтиҗәне электрон документ рәвешендә җибәргәндә – бәяләмәгә кул кую һәм аны теркәү көнендә;

нәтиҗәне кәгазьдә мөрәҗәгать итүчегә Комитетта шәхсән биргәндә – мөрәҗәгать итүче килгән көнне;

нәтиҗәне почта аша җибәргәндә – бәяләмәгә кул кую һәм аны теркәү көнендә;

нәтиҗәне КФҮ аша биргәндә – мөрәҗәгать итүчегә бәяләмәнең кәгазь нөсхәсе КФҮ мөрәҗәгать иткән көнне бирелә.

3.7. Дәүләт хезмәте алгарышлы (проактив) режимда күрсәтелми.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гарызнамәне карау статусын үзгәртү турында мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итү ысуллары

4.1. Техник мөмкинлек булганда, мөрәҗәгать итүчегә аның гарызнамәсенең әлеге Регламентта билгеләнгән статусы үзгәрүе турында (гарызнамәне кабул итү һәм теркәү турында; мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү (җибәрү) турында), шулай ук мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтүнең әлеге этабында санап үтелгән ысулларның берсе белән башкарырга тиешле алда торган адымнары һәм гамәлләре турында хәбәр ителә:

Бердәм портал ярдәмендә;

Республика порталы аша;

мөрәҗәгать итүче Комитетка шәхсән кергәндә (телдән мәгълүмат бирү юлы белән).

Хуҗалык буенча үзләштерелергә тиешле җир кишәрлегенә дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасы актына бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымта

Шартлы билгеләр һәм кыскартулар исемлеге

ГИКЭ акты – хуҗалык буенча үзләштерелергә тиешле җир кишәрлегенә дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасы акты.

Бәяләмә – Татарстан Республикасы Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты тарафыннан хуҗалык буенча үзләштерелергә тиешле җир кишәрлегенә дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасы актына бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе.

Мөрәҗәгать итүче – хуҗалык буенча үзләштерелергә тиешле җир кишәрлегенә дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасы актына бәяләмә бирүне сорап мөрәҗәгать иткән гражданин, шәхси эшкуар, юридик зат.

Мөрәҗәгать итүченең вәкиле – законнарда билгеләнгән тәртиптә бирелгән ышанычнамә нигезендә эш итүче зат.

Комитет – әлеге дәүләт хезмәтен күрсәтә торган Татарстан Республикасы Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты.

Регламент – хуҗалык буенча үзләштерелергә тиешле җир кишәрлегенә дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасы актына бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты.

Бердәм портал – Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы (https://www.gosuslugi.ru/);

Республика порталы – Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы ((https://uslugi.tatarsta№.ru/).

КФҮ – дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре.

63-ФЗ номерлы федераль закон – «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы федераль закон.

Хуҗалык буенча үзләштерелергә тиешле җир кишәрлегенә дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасы актына бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 2 нче кушымта

Мөрәҗәгать итүчеләрнең категорияләре (билгеләре) идентификаторлары

| № | Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе | Мөрәҗәгать итүченең аерым билгесе исеме | Мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым билгесе идентификаторы |
|---|---|---|---|
| 1. | Йомгаклау | Гражданин, шәхси эшкуар | 1А |
| 2. | | Гражданинның, шәхси эшкуарның вәкиле | 2А |
| 3. | | Юридик зат | 3А |
| 4. | | Юридик зат вәкиле | 4А |

Хуҗалык буенча үзләштерелергә тиешле җир кишәрлегенә дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасы актына бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 3 нче кушымта

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге

| № | Документлар исемлеге | Мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым билгесе идентификаторы | Тапшыру ысулы |
|---|---|---|---|
| *Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен үзе тапшыра торган документлар* | | | |
| 1. | дәүләт хезмәте күрсәтү турында гарызнамә:<br>әлеге Регламентның 5 нче кушымтасында китерелгән үрнәктәге документ рәвешендә | 1А, 2А, 3А, 4А | Бердәм портал; Республика порталы (гарызнамәнең электрон формасына тиешле белешмәләр кертү юлы белән тутырыла, 63-ФЗ номерлы федераль закон таләпләре нигезендә имзалана), Комитетка шәхсән; КФҮ аша; почта юлламасы белән |
| 2. | шәхесне раслаучы документы | 1А, 2А, 3А, 4А | Бердәм портал; Республика порталы (шәхесне таныклый торган документ белешмәләре «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне электрон формада күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик бәйләнешен тәэмин итә торган инфраструктурада Бердәм идентификация һәм аутентификация системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында исәпкә алу язуын раслаганда тикшерелә), Комитетка |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | шәхсән; КФҮ аша; |
| 3 | мөрәҗәгать итүче вәкиленең вәкаләтләрен таныклаучы документ | 2А, 4А | Бердәм портал; Республика порталы, Комитетка шәхсән; КФҮ аша; почта аша |
| 4 | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасы турында нигезләмә раслау хакында» 2024 елның 25 апрелендәге 530 номерлы карары белән расланган Дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасы турында нигезләмә нигезендә рәсмиләштерелгән һәм көчәйтелгән квалификацияле имза белән имзаланган, PDF документ формасытнда йөртелә торган, электрон рәвештә беркетелгән барлык документлар һәм материаллар белән бергә ГИКЭ акты. ГИКЭ актында квалификацияле электрон имза штампы күрсәтелергә яки экспертлар имзасы ачкычларын раслый торган файл булырга тиеш. | 1А, 2А, 3А, 4А | Бердәм портал; Республика порталы, Комитетка шәхсән; КФҮ аша; почта аша |
| *Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында тапшырылырга тиешле, мөрәҗәгать итүче үз инициативасы белән тапшырырга хокуклы булган документлар каралмаган.* | | | |

Хуҗалык буенча үзләштерелергә тиешле җир кишәрлегенә дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасы актына бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 4 нче кушымта

## Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гарызнамәне һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге һәм дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге

| № | Гарызнамәне һәм документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр исемлеге | Мөрәҗәгать итүченең идентификаторы |
|---|---|---|
| 1 | дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гарызнамә рәвешендә мәҗбүри кырларны дөрес тутырмау (төгәл түгел, дөрес яисә тулысынча тутырмау), шул исәптән Бердәм порталда, Республика порталында гарызнамәнең интерактив рәвешендә дә | 1А, 2А, 3А, 4А |
| 2 | тапшырылган документлар дәүләт хезмәтен сорап мөрәҗәгать итү вакытына үз көчен югалткан (шәхесне таныклаучы документ, мөрәҗәгать итүче вәкиле вәкаләтләрен таныклаучы документ) | 1А, 2А, 3А, 4А |
| 3 | мөрәҗәгать итүче тарафыннан кәгазьдә тапшырылган документларда Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган чистартылган һәм текстны төзәткән урыннар булуы | 1А, 2А, 3А, 4А |
| 4 | электрон рәвештә тапшырылган документларда дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлардагы мәгълүматны һәм белешмәләрне тулы күләмдә файдаланырга мөмкинлек бирми торган зарарланган урыннар булуы | 1А, 2А, 3А, 4А |
| 5 | электрон рәвештәге гарызнамә һәм башка документлар электрон имза белән «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы федераль закон таләпләрен бозып имзаланган | 1А, 2А, 3А, 4А |
| Дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган | | |
| Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр каралмаган | | |

Хуҗалык буенча үзләштерелергә тиешле җир кишәрлегенә дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасы актына бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 5 нче кушымта

Татарстан Республикасы Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты рәисенә
кемнән: ______________________
(физик зат өчен: Ф.И.А. (ата исеме – булган очракта), шәхесне таныклаучы документның исеме, сериясе, номеры, бирелү датасы, кем тарафыннан бирелгән, телефон, электрон почта адресы; вәкил өчен: вәкил вәкаләтләрен раслаучы өстәмә документ; ШЭ өчен: өстәмә рәвештә ОГРНИП, ИНН; юридик зат өчен: тулы исеме, оештыру-хокукый формасы, ИНН, ОГРН)

Хуҗалык буенча үзләштерелергә тиешле җир кишәрлегенә дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасы актына бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү турында гарызнамә

Хуҗалык буенча үзләштерелергә тиешле җир кишәрлегенә дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасы актына бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү турында үтенәм:

дәүләт тарихи-мәдәни экспертиза актының тулы исеме: ________;

дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасы актын рәсмиләштерү датасы: ____________.

Кушымталар: ☐ Барлык теркәлә торган документлар һәм материаллар белән дәүләт тарихи-мәдәни экспертиза акты, ☐ SIG форматында экспертның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән беркетелгән файл, ☐ Башка документлар.

Хуҗалык буенча үзләштерелергә тиешле җир кишәрлегенә дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасы актына бәяләмәне түбәндәгечә бирүегезне (җибәрүегезне) сорыйм (кирәклесен ассызыкларга):

шәхсән, адрес буенча почта аша__________________ , Бердәм портал яисә Республика порталы, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге аша.

__ _____ ____ (имза, гарызнамәне бирү датасы: (ФИА (ата исеме – булган очракта))

Хуҗалык буенча үзләштерелергә тиешле җир кишәрлегенә дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасы актына бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 6 нчы кушымта

Кемгә: ____________________
(физик затлар өчен: Ф.И.А. (ата исеме – булган очракта), физик зат яки юридик затның тулы исеме)

Хуҗалык буенча үзләштерелергә тиешле җир кишәрлегенә дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасы актына бәяләмә

Хуҗалык буенча үзләштерелергә тиешле җир кишәрлегенә дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасы актын бирү турында ________ № _________ гарызнамә нигезендә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасы турында нигезләмә раслау турында» 2024 елның 25 апрелендәге 530 номерлы карары белән расланган Дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасы турында нигезләмәнең (алга таба – Нигезләмә) 30, 31 пунктлары таләпләренә туры китереп, хуҗалык буенча үзләштерелергә тиешле җир кишәрлегенә дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасы актына бәяләмә бирү турында дәүләт тарихи-мәдәни экспертиза акты каралды ____________________________________________________________
(тарихи-мәдәни экспертиза актының тулы исеме)
_____________, Россия Федерациясенең Мәдәният министрлыгы тарафыннан аттестацияләнгән
(дата)
дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасын уздыру буенча эксперт тарафыннан төзелде ____________________ (алга таба – ГИКЭ акты).
Ф.И.А. (ата исеме – булган очракта)

Иҗтимагый фикер алышу барышында (кирәклесен ассызыкларга):
тәкъдимнәр килмәде;
түбәндәге тәкъдимнәр килде: ___________________________________
(Комитетның искәрмәләре һәм позициясе күрсәтелә)

ГИКЭ актын, аңа беркетелгән документларны һәм материалларны карау нәтиҗәләре буенча экспертиза бәяләмәсендә бәян ителгән нәтиҗәләр белән килешү/ килешмәү турында карар кабул ителде.

Риза булмауның сәбәпләре: _________________ (риза булмау очрагында бер яки берничә вариантны сайлау:

экспертиза бәяләмәсенең мәдәни мирас объектларын дәүләт саклавы өлкәсендәге Россия Федерациясе законнарына туры килмәве;

экспертиза бәяләмәсен рәсмиләштергән көннән алып 3 еллык срокның тәмамлануы;

экспертиза үткәрүнең билгеләнгән тәртибен бозу;

экспертиза бәяләмәсенә кул куйган экспертка карата Нигезләмәнең 5 пунктында каралган хәлләрне ачыклау;

экспертиза уздыру өчен Нигезләмәнең 15 пунктында күрсәтелгән, дөрес булмаган белешмәләр булган документларны тапшыру.

Өстәмә мәгълүмат (булган очракта): _____________

Рәис ______________________
(имза, Ф.И.А. (ата исеме – булган очракта))